Әлмәт шәһәре Башкарма комитеты
КАРАРЫ

«05» ноябрь 2019 ел №93

Җир кишәрлегеннән һәм капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2009 елның 25 декабрендәге 366 номерлы карары белән расланган «Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре нигезендә, Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторын раслау турында» 2015 елның 30 сентябрендәге 709 номерлы боерыгы, Әлмәт шәһәре башлыгының 2019 елның 4 сентябрендәге 28 номерлы «Җәмәгать тыңлауларын билгеләү турында»карары нигезендә 2019 елның 21 октябрендәге 8351и номерлы гавами тыңлаулар нәтиҗәләре бәяләмәсе нигезендә (“Альметьевский вестник” газетасы 2019 елның 24 октябрендәге 36 номерлы басмасы),

ӘЛМӘТ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ КАРАР БИРӘ:

1. Җир кишәрлегеннән һәм капиталь төзелеш объектыннан шартлы рәвештә файдалану төренә - «кафе, ашамлыклар, барлар, рестораннар, шул исәптән күп катлы торак йортларның 1-2 катында», рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторы буенча 4.6 нчы код - «җәмәгать туклануы», кадастор номеры 16:45:010103:59, 16:45:010103:2409 16:45:010103:2226 һәм 16: 45: 010103: 2226 булган, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәре, 8 Март ур., . 23А йорт адресы буенча урнашкан җир кишәрлекләренә карата капиталь төзелеш объектын файдалануны рөхсәт итәргә.

2. «Әлмәт муниципаль районының архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе» муниципаль бюджет учреждениесенә (Мордагулова Р.Р.) әлеге карарны «Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча федераль дәүләт бюджет учреждениесе филиалына (Мирасова А.А.) җир кадастр документациясенә тиешле үзгәрешләр кертү өчен җибәрергә.

3. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чykканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны төзелеш буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасары А.А. Мөхәммәтҗанова йөкләргә.

Шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе Л.Ф. Валеев